МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

19.03.2019 № 2607/19

На №_____от_____

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлеге (идарәләре) җитәкчеләренә

Шаяннар һәм тапкырлар клубы фестивале турында

Хөрмәтле җитәкчеләр!

2019 елның апрель аенда Казан шәһәрендә «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» республика балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмасы (алга таба – ШТК) татар телендә ШТК фестивале уеннарын оештыра. Фестивальда катнашу өчен Татарстан Республикасы белем бирү оешмалары укучылары чакырыла.

Тулырак мәгълүмат алу өчен «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Р.Г.Кадыровка мөрәҗәгать итергә мөмкин (Shtk-tat@mail.ru, тел.: +7 (927)424-55-18).

Кушымта: 3 б. 1 нөсхәдә.

Министрның беренче урынбасары И.Г.Һадиуллин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 50DC6D5E210274BDE911E3432112A156
Владелец: Хадиуллин Ильсур Гараевич
Действителен с 11.03.2019 до 11.06.2020

Л.И.Галимова
(843) 294-95-10

Иҗтимагый Яшләр Оешмасы “Шаяннар
һәм Тапкырлар клубы”
www.shtk-tat.ru
info@shtk-tat.ru

Региональная Детская Молодежная
Общественная Организация «Шаяннар
Тапкырлар Клубы» (Клуб Веселых и
Находчивых РТ)

Шаяннар һәм Тапкырлар клубының
2018-2019нчы уку елына эшен оештыру турында

НИГЕЗЛӘМӘ

ШТК уеннары 2019 елдан яңадан сәхнәгә кайта. Төрле мәктәпләрдән теләкләрен белдергән актив балалар командаларын җыячак. Әлеге уеннарда Казан балалары гына түгел, ә башка районнардан, хәтта башка регионнардан килгән балалар да катнаша ала. Һәр командага ярдәмгә кураторлар билгеләнә. Командалар әзерләнгән вакытта, параллель рәвештә, кызыклы чаралар да үткәрелә. Бу исә балаларны таныштыру, бердәм команда туплау, тәрбияләү өчен дә бик мөһим. Соңыннан зур ШТК концерты оештырылачак. Балаларның чыгышларын карарга танылган татар алып баручылары, блоггерлар, актер һәм җырчылар, КВН легендалары һәм күп төрле зыялы шәхесләр чакырылачак

Максат: ШТК уеннары ярдәмендә татар теленең сафлыгын саклау һәм балаларның актив, иҗади үсешен тәэмин итү.

Бурычлар:

1. Балаларның иҗади һәм интеллектуаль потенциалын үстерү;
2. Татар мәдәниятының мираслары белән танышу;
3. Татар телен үстерүдә өстәмә җирлек тудыру;
4. Балаларга буш вакытларын файдалы һәм дөрес үткәрер өчен мәйданчыклар булдыру;
5. Баланың шәхси үзүсеше, командада эшләүгә өйрәнүе;
6. Татар эстрадасының зыялы шәхесләре белән очрашулар;
7. Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр тудыру

Катнашучылар: бәйгедә 6-10 сыйныф укучылары төркемләп тә, аерым гына да катнаша ала.

2018 елга кадәр ШТК эшчәнлегенең нәтиҗәләре:

1. 2010-2018 еллар арасында **19 Республика күләм ШТК уеннары узды**. Уеннар Казанның төп мәдәни йортларында уздырылды (“Ак барс” яшьләр үзәге, “Казан” милли мәдәният үзәге, “Сәйдәш” мәдәният йорты, “Татарстан халыклары Ассамблеясы һәм Дуслык Йорты”, «К.Тинчурин театры» ....) **500** бала даими рәвештә уеннарда катнашты, Россияның (Самара, Уфа) һәм Татарстанның түбәкләреннән командалар катнашты (Казан, Яр Чаллы, Актаныш, Арча, Балтач, Мамадыш).

2. **10** Республика күләм һәм төбәкара сәламәтләндерү сменалар (“Пионер” Казан, “Балкыш” Тукай р-ны, “Романтик” Балтач р-ны, “Шатлык” Арча р-ны, “Бүләк” Актаныш р-ны базаларында) үткәрелде. **1700 бала**

3. Казан мәктәп укучылары очен “якшәмбе” чаралары уздырыла. Балалар кураторлар белән интелектуаль, спорт, иҗади бәйгеләрендә катнаштылар.

2019 уку елы сезонына уен календаре:

- Фестиваль - Апрель аенда
- Ярым финал - Октябрь аенда
- Финал - Декабрь аенда

“Татарстан халыклары Ассамблеясы һәм Дуслык Йорты”нда ШТК уеннары узачак.

Эгэр сезгэ безнен оешманын юнэлеше ошаса, сездэн ризалык гына кирэк, ботен эшчэнленлекне без узебез алып барабыз, +7 (927) 424-55-18 Кадыров Руслан (оешманын житэкчесе) блн элемтэгэ чыга аласыз.

Хөрмәт белән, Кадыров Р.Г.
РДМОО «Шаяннар Тапкырлар Клубы» җитәкчесе.